Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Шаршады авыл җирлегенең Шаршады торак пунктында **ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2019 ел, 15 октябрь №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Шаршады авыл җирлеге Шаршады торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ:**

1. I группа инвалидлардан, ялгыз яшәүче өлкән кешеләрдән (80 яшькә җиткән), көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, Шаршады авыл җирлеге Шаршады авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, үзара салым акчасын 2020 елда 400 сум күләмендә кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирлектә әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

-янгын сүндерү машинасы сатып алу;
-янгын сүндерү машинасын тоту өчен корылма төзекләндерү.

3. Гражданнарның җыен нәтиҗәләрен Шаршады авыл җирлеге мәгълүмати стендларында урнаштыру, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
муниципаль берәмлек Башлыгы, Совет Рәисе В.Х. БАҺАВЕТДИНОВ

Совет сельского поселения
Шаршады авыл җирлеге Советы